СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“16” октябрь 2019 ел** **№ 107**

**Утар-Аты авыл җирлеге Советының “Физик затларның мөлкәтенә салым турында” 2015 елның 3 ноябрендәге 8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясының беренче өлеше һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Утар-Аты авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 8 номерлы «Физик затларның мөлкәтенә салым турында» Карарына (Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябрендәге 76 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 2 пунктында:

1.1.1. 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) 0,2 процент:
фатирга, фатирның өлешенә;
бүлмәгә карата;»;

1.1.2. 3 нче пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«торак йортлар, торак йортларның өлешләре;».

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салымны исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан, игълан ителгән көннән бер ай үзганнан соң гына үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г. Мөхәммәтгалиева